**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№9594**
**16.09.2026**

Яр Чаллы шәһәренең «Комсомолец» спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Тернәкләндерү үзәгенә йөрү буенча Яр Чаллы шәһәренең «Комсомолец» спорт мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, 1 сәгатькә 450 (дүрт йөз илле) сум күләмендә расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Комсомолец» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны раслау турында» 2021 елның 2 мартындагы 1429 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов